ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

2020 ел, 5 октябрь №4

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы **к а р а р и т т е**:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2016 елның 9 февралендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.3 пунктның 4 пунктчасында "хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр" сүзләрен өстәргә";

2) 8.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы сүзләрен» «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләренә алмаштырырга.

3) 19.1 пунктның 4 пунктчасында "(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен"сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башлыгы урынбасары Л.Т.Хантимировка йөкләргә.

Апас муниципаль районы
Башлыгы
Апас муниципаль районы
Рәисе **Р.Ф. Хисамутдинов**